КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 сентябрь г.Казань № 888

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 9 август, 643 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында һәм гражданнарның кайбер категорияләрен торак урыннар белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 8 декабрь, ФЗ-342 нче Федераль закон нигезендә торак урыннар белән тәэмин ителүче гражданнарга милеккә түләүсез яки социаль найм буенча торак урыннар бирү, аларга торак урын сатып алу йә төзү өчен бер тапкыр акчалата түләү бирү кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында һәм гражданнарның кайбер категорияләрен торак урыннар белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 8 декабрь, ФЗ-342 нче Федераль закон нигезендә торак урыннар белән тәэмин ителүче гражданнарга милеккә түләүсез яки социаль найм буенча торак урыннар бирү, аларга торак урын сатып алу йә төзү өчен бер тапкыр акчалата түләү бирү кагыйдәләрен раслау хакында» 2011 ел, 9 август, 643 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 февраль, 124 нче; 2015 ел, 24 октябрь, 800 нче; 2016 ел, 19 апрель, 238 нче; 2016 ел, 27 декабрь, 1009 нчы; 2020 ел, 24 февраль, 131 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында һәм гражданнарның кайбер

категорияләрен торак урыннар белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 8 декабрь, ФЗ-342 нче Федераль закон нигезендә торак урыннар белән тәэмин ителүче гражданнарга милеккә түләүсез яки социаль найм буенча торак урыннар бирү, аларга торак урын сатып алу йә төзү өчен бер тапкыр акчалата түләү бирү кагыйдәләренә, 2 нче пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«г) хәрби хезмәтнең гомуми дәвамлылыгына карамастан, хәрби хезмәт үтү чорында һәлак булган (вафат булган) хәрби хезмәткәрләрнең (хәрби хезмәткәрләрне торак белән тәэмин итүнең җыелып бара торган ипотека системасында катнашкан хәрби хезмәткәрләрдән тыш) гаилә әгъзалары, шулай ук контракт буенча хәрби хезмәт үткән һәм, хәрби хезмәттә булуның иң чик яшенә җитү, сәламәтлегенең торышы буенча яки оештыру-штат чараларына бәйле рәвештә, хәрби хезмәттән азат ителгәннән соң һәлак булган (вафат булган), хәрби хезмәтнең гомуми дәвамлылыгы календарь белән исәпләгәндә 10 ел һәм аннан күбрәк, ә хәрби хезмәтнең гомуми дәвамлылыгы, азат итү нигезенә карамастан, 20 ел һәм аннан күбрәк тәшкил иткән гражданнарның гаилә әгъзалары.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин